ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 315 от «26» 08 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 июнендәге 246 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 47.2, 160.1 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 июнендәге 246 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге җирләр һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тану Тәртибенә (алга таба- Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 нче пунктында:

а) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;»;

б) 2.1пунктчаны үз көчен югалтты дип таныргa;

в) 4һәм 5 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4) штрафка тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны; шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалткан җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану;

5) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган

0000012326

нигезләмә буенча башкарма документны түләтүчегә кайтарганда, күләме банкротлык турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килү датасыннан биш елдан артык узган булса, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару турында карар чыгару;

г) түбәндәге эчтәлектәге 5.1 пунктча өстәргә:

"5.1) банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару яки банкротлык турындагы эшне туктату турында акт кабул итү банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле;".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми http://www.mamadysh.tatarstan.ru сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.М.Никифоров